**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» 2004 елның 27 мартындагы ПУ-290 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы, 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 июлендәге 461 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына, Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

В.В. Виниченконың – «Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча)»;

Э.Р. Долотказинаның – «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыятенең дәүләт органнары белән элемтәләр хезмәте менеджеры (килешү буенча)»;

Р.М. Карповның – «Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 11 июнь
№ 439